**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

Бирючевка авылы  № 19  "18" апрель 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2020 елның 15 июненән 172 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2020 елның 15 июненән 172 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дерес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында карар кабул итү тәртибенең 3 пунктндагы ике абзацында, 4 пунктында, 5 пунктындагы ике абзацында, 6 пунктындагы беренче абзацында, беренче абзацында, 7 пунктындагы өченче, 11 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен тиешле килешләрдә «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырып үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo. tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны йөкләргә Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә.

Рәис  З.Г.Солтанова